**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 декабрендәге 4338 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы һәм 2025 елның 5 ноябрендәге под-1761/25 номерлы «2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү өчен тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында”гы әмеренә үзгәрешләр кертү хакында»гы әмерләренә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы карары (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 июлендәге 2335 номерлы, 2024 елның 4 октябрендәге 4198 номерлы, 2024 елның 25 декабрендәге 5345 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 1345 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән

расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәриквалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүматитехник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең II бүлегендәге 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе структурасына керә торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем** |
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары | - | - | 24598,0 |

<table>
<tr><th rowspan="2">Квалификация дәрәҗәсе</th><th rowspan="2">Вазифа атамасы</th><th colspan="3">Айга төп оклад күләме, сум</th></tr>
<tr><th>Төп гомуми белем, урта гомуми белем</th><th>Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем</th><th>Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем</th></tr>
<tr><td rowspan="2"></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы)</td><td>-</td><td>-</td><td>24690,0»</td></tr>
</table>

1.2. Нигезләмәгә кушымтада «Кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 1.14 пунктча белән тулыландырырга:

| **№ т/б** | **Мактаулы исем, бүләк атамасы** |
|---|---|
| «1.14 | “Һөнәргә тугрылык өчен” күкрәк билгесе» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**